ЧАСТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«ТАТНЕФТЬ-ШКОЛА» г. АЛЬМЕТЬЕВСКА

| Рассмотрена и принята<br>на педагогическом совете<br>Протокол № 1<br>«27» августа 2020 г. | СОГЛАСОВАНО:<br>Зам. директора по УВР<br>ЧОУ «Татнефть-школа»<br>____________ Н.А.Шокурова<br>«27»_____08_____20__г. | УТВЕРЖДАЮ:<br>Директор<br>ЧОУ «Татнефть-школа»<br>____________ О.А.Калягина<br>Приказ № 103<br>«27»_____08_____2020 г. |
|---|---|---|

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**учебного предмета «Литературное чтение на родном языке»**

**для 1-4 классов**

**на 2020-2021 учебный год**

**Программу разработала и реализует**
**учитель татарского языка**
**Сафина Гульназ Исмагиловна**

# ӘДӘБИЯТ УКЫТУ
# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

1, 2, 3, 4 нче сыйныфында әдәби укудан эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

1. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен әдәби укудан программа (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 1-4 нче сыйныфлар / Ф. Ш. Гарифуллина, И.Х. Мияссарова. – Казан: “Мәгариф - Вакыт” нәшр., 2015. – 47 б.
2. Әдәби уку : рус телендә башл. гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 1 нче с-ф. / [Ф.Ф. Гарифуллина, И.Х. Мияссарова: рәссамы А. Фомина]. – Казан : “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2018. 87б.: рәс. б-н.
3. Әлмәт шәһәре ЧОУ “Татнефть-школа”ның 2018-2019 нчы уку елына укыту планы
4. Әлмәт шәһәре ЧОУ “Татнефть-школа”ның 2018-2019 нчы уку елына еллык календарь графигы
5. Әлмәт шәһәре ЧОУ “Татнефть-школа”ның ”Положение о структуре, порядке разработки и утверждения рабочих программ учебных курсов, предметов, дисциплин (модулей)”

**Аңлатма язуы**

“Әдәби уку” курсы башлангыч гомуми белем бирү системасында кече яшьтәге мәктәп укучыларның интеллектуаль, сөйләм, эмоциональ, рухи-әхлакый үсешенә, әйтмә һәм язма сөйләмне куллана белү күнекмәләренә нигез салучы төп предметларның берсе булып тора.

Әдәби уку программасын үзләштергәндә, әлеге курс шәхси, предмет һәм предметара нәтиҗәләргә ирешүгә һәм башлангыч мәктәптә башка предметларны уңышлы үзләштерүгә нигез булып тора.

**Укыту предметына гомуми характеристика**

“Әдәби уку” курсы түбәндәге концептуаль положениеләрне (таләпләрне) истә тотып төзелде:

- өйрәнү (укыту) баланың шәхси үсешен, аның интеллектын һәм сөйләм эшчәнлегенең төп төрләрен (тыңлау, сөйләү, уку һәм язу) формалаштыруны тәэмин итә;
- өйрәнү (уку) нәтиҗәсендә, кече яшьтәге мәктәп укучысының китап уку эшчәнлеге, уку эшчәнлеге компонентлары, шулай ук универсаль уку гамәлләре формалаша;
- дифференцияле укыту һәр баланың шәхси мөмкинлекләрен исәпкә ала.

Әсәр һәм китап белән эшләргә өйрәтүнең бәйләнештә алып барылуы әлеге программаның характерлы билгесе булып тора. Әсәрләрне өйрәнгәндә, һәрдаим

уку, әдәби, мәгълүмати балалар китабы белән эшләргә өйрәтү бара, мөстәкыйль укуга кызыксыну үстерелә.

Программада укырга өйрәтүгә һәм китап белән эшләүгә аерым дәресләр каралмаган. Әмма әдәби уку дәресләрендә кече яшьтәге мәктәп балаларының әдәби белем бурычлары комплекслы хәл ителә: уку күнекмәләре формалаша, эмоциональ, эстетик һәм әдәби үсеш бурычлары хәл ителә. Чөнки уку бала өчен ул – эш тә, хезмәт тә, иҗат та, яңа ачышлар да һәм үзбәя дә.

**Курс төзелеше принциплары**

• *системалылык принцибы* кече яшьтәге мәктәп балаларын укыту, тәрбияләү һәм аларда үсеш булдыру бурычларын комплекслы хәл итә;

• *эстетик принцип* әдәби уку курсына кергән әсәрләрне билгеле бер шарт белән чикли. Кече яшьтәге мәктәп укучыларын балалар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру нәтиҗәсендә, балаларда эстетик зәвык һәм китап укуга ихтирамлы караш формалаштырыла;

• *эмоциональлек принцибы* яңа гына китап укый башлаган баланың эмоциональ хисләренә әдәби әсәрнең йогынтысын исәпкә ала;

• *дәвамчанлык принцибы* әдәби белем бирүнең төрле этапларының татар теле, әйләнә-тирә дөнья, музыка һәм рәсем сәнгате белән бәйләнешен тәшкил итә.

«Әдәби уку» курсын төзегәндә, системалылык принцибын исәпкә алып, аның эчтәлегендә түбәндәге таләпләр формалаштырылды:

• дәреслек эчтәлеге тематик приципка нигезләнгән бүлекләрдән тора. Әсәрләр кече яшьтәге мәктәп укучыларының яшь һәм психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып сайланды, кече яшьтәге мәктәп укучысын үз халкының һәм башка милләт халыкларының мәдәнияте һәм әдәбияты белән таныштыруга юнәлтелде;

• практик юнәлеш характерында булган тыңлау, уку, телдән һәм язма сөйләм төрләре һәр өйрәнелә торган бүлеккә кертелде;

• әдәби төшенчәләрне эзлекле кертә бару әдәби үсеш һәм китап укучы компетенциясе формалашуга ярдәм итә;

• мөстәкыйль уку эшчәнлеге формалаштыру буенча системалы (эзлекле) эш һәр сыйныфта, һәр бүлектә алып барыла, сыйныфтан сыйныфка катлауландырыла;

• дәреслектә бирелгән иҗади биремнәр системасы укучыларның белем дәрәҗәсен һәм шәхси мөмкинлекләрен исәпкә алырга ярдәм итә;

• мәгълүмат туплау (әсәрдән билгеле бер информацияне табу, сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурсларга мөрәҗәгать итү) барлык сыйныфларда да эзлекле рәвештә формалаштырыла.

**Башлангыч мәктәптә «Әдәби уку» курсының специфик үзенчәлекләре**

• уку осталыгы һәм уку техникасы буенча эшне яраштыру;

• текст белән эшләү, әдәби әсәрләрне сүз сәнгате буларак тикшерү;

• бер үк вакытта әдәби әсәр теле һәм укучыларның сөйләме өстендә эш;

• өйрәтүнең төп объекты буларак, балалар китабы һәм әдәби әсәрләр өстендә эшнең бердәмлеге;

• әдәби һәм фәнни-популяр әсәрләрне аера белү;

• әсәрне тулаем аңларга ярдәм итә торган әдәби төшенчәләрне үзләштерү;

• укучыларның иҗади эшчәнлеге белән яраштырып, әдәби әсәрләрне үзләштерү.

Әдәби уку курсының төп максаты — укучыга китап укучы булырга, әдәбият дөньясының бай мирасын үзләштерергә, аның китап уку тәҗрибәсен баетырга ярдәм итү. Китап уку күнекмәләрен үстерү телдән һәм язма сөйләмнең төп төрләрен үзләштерүне: әсәр текстын аңлау сәләтен, әдәби сүзне тыңлау һәм ишетүне, эчтән һәм кычкырып укуны, текстны фактлар дәрәҗәсендә генә түгел, мәгънәсе буенча аңлауны (үз фикереңне, эмоциональ мөнәсәбәтеңне белдерә белүне); укыганны хәтердә яңадан булдыруны (геройлар, вакыйгаларны күз алдына китерү) һәм әсәр текстын төрле вариантта — тулы итеп, сайлап алып, кыскача, вакыйгаларны үзгәртеп иҗади сөйләп бирүне тәэмин итүне күз алдында тота.

**«Әдәби уку» курсының бурычлары**

• укучының әдәби әсәрне тулысынча аңлап кабул итүен, текстны һәм аның әдәби формалары үзенчәлекләрен аңлауны тәэмин итү;

• укучыларны язучы фикерен аңларга, үз фикерләрен булдырырга, аларны формалаштырырга һәм аңлатып бирә белергә өйрәтү (китап укучы позициясе булдыру);

• кычкырып, эчтән, сәнгатьле итеп уку күнекмәләрен камилләштерү; укуның төп төрләреннән (танышу максатыннан, өйрәнү максатыннан, эзләнү, карап чыгу максатыннан уку) файдалана белү;

• уку прцессында укучыларны иҗади эшчәнлеккә җәлеп итү, парлап һәм төркемдә эшләргә өйрәтү;

• әдәбиятны сүз сәнгате буларак аңлау өчен кирәкле әдәби (литературоведческие) күзаллауны формалаштыру;

• әдәби киңлек (пространство) булдыру, аңлап һәм универсаль уку эшчәнлеге формалаштыру шартларын тәэмин итүче, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә һәм яшь үзенчәлекләренә туры килә торган уку тирәлеген киңәйтү. Программада уку тирәлеге дәрестә уку, өстәмә уку һәм мөстәкыйль уку өчен («Китап киштәсе» рубрикасы) тәкъдим ителгән әсәрләр хисабына формалаштырыла.

**Әдәби уку дәресләренең укыту планындагы урыны**

1 нче сыйныфта әдәби укуны өйрәнү «Грамотага өйрәтү» курсында тыңлау дәресләрендә башлана, дәвамлылыгы сыйныфның әзерлек дәрәҗәсенә, өйрәнү темпына, программага туры килә торган укыту чаралары һәм укытучының профессиональ (һөнәри) осталыгына бәйле. 2 нче сыйныфтан башлап, әдәби укуга атнага 2 сәгать вакыт бирелә.

## УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

### Уку күнекмәләрен үстерү

Уку күнекмәләрен үстерү кычкырып укудан эчтән уку формасына күчү нәтиҗәсендә башкарыла. Укуны үзләштерү беренче уку елында — сүзләрне тулысынча уку алымнарын формалаштыруны, сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне интонацион бәйләүне (берләштерүне); икенче елны уку тизлеген арттыру һәм эчтән укуны кертүне күз алдында тота. 3—4 нче сыйныфларда эчтән уку темпын үстерү һәм сәнгатьле уку алымнарын куллану (уку бурычларын аңлау һәм шуңа бәйле рәвештә сәнгатьлелекнең интонацион чараларын сайлый белү) каралган. Укучыларның үзләштерү темпы төрлелеген исәпкә алып, мәктәпкә укый белеп килгән һәм уку процессында артта калган укучылар белән дә шәхси якын килеп эшләүне оештыру мөһим. Моның өчен укыту чараларында төрле дәрәҗәдәге биремнәр бирелгән.

**Әсәрне кабул итүне (үзләштерүне) үстерү**

Китап укучы бала, һәрдаим үзенең рухи дөньясын үстерә барып, әдәбиятка хас кыйммәтне аңлый башлый. Шуңа күрә әдәби әсәрне аңлау характеры һәм тулылыгы китап уку тәҗрибәсенә, аның автор уена туры килгән сүзле образлар төзи алу осталыгына бәйле.

**1 нче сыйныфта** укучыларда уку күнекмәләре юк яки тиешенчә түгел, шунлыктан китап укучы буларак әсәрне зиһенгә алу (үзләштерү) әдәби әсәрләрне тыңлау дәресләрендә формалаша.

**2 нче сыйныфта** тыңлау өчен тәкъдим ителгән әсәрләр дәреслектә «Тыңла» рубрикасына кертелгән. Күп кенә укучылар уку күнекмәләренә инде ия һәм текст белән мөстәкыйль эшли ала, ләкин, тәҗрибә күрсәткәнчә, яңа китап укый башлаган укучы тыңланган әсәрне кызыксыныбрак укый.

**2 нче сыйныфта** ук аналитик уку (вакыйгалар чылбырын, геройлар һәм аларның эш-гамәлләрен аерып күрсәтү) үткәрелә. Укытучы балаларга «Әсәр ничек башлана?», «Алга таба нәрсә булган?», «Нинди вакыйгалар сезне дулкынландырды?», «Әсәр ничек тәмамланган?» кебек сораулар бирә. Әсәрнең формасы: әсәрнең жанр төре, жанр үзенчәлекләре, вакыйгаларны, геройларны сурәтләүче мөһим сүзләр билгеләтелә.

**3—4 нче сыйныфларда** укучының әдәби әсәрне мөстәкыйль укуы тулы күләмендә башлана: кычкырып һәм эчтән укый белү, текстны тыңлау һәм ишетү; тыңлаганда һәм мөстәкыйль укыганда әсәр эчтәлеген аңлау; сорауларга җавап бирү һәм сораулар бирә белү; әсәр тексты белән эшли белү кебек эшләр башкарыла.

**Әдәби төшенчәләр белән танышу**

**1—2 нче сыйныфларга** укучылар әсәр жанрлары һәм темалары белән гамәли танышалар, әкият, шигырь, хикәя үзенчәлекләренә төшенәләр. Авторларның төрле жанрдагы әсәрләре турындагы күзаллаулары тулыландырыла (байый).

**3 нче сыйныфтан** әдәби төшенчәләр тулыландырыла, төрле жанрдагы әсәрләрнең үзенчәлекләре аерып күрсәтелә, шул рәвешле балаларның уку тирәлеге киңәя, әсәрләр катлауландырыла.

**Сөйләм осталыгы үсеше (дәрәҗәсе)**

Программада текстагы сүзне «күрә» белү, әсәр контекстында аны аңлый, мәгънә төсмерләрен аера, ни өчен язучы, шагыйрь башка сүзне түгел, ә менә нәкъ

шушы сүзне сайлаганын, бу сүзнең геройны ничек характерлавын һәм авторның үз героена мөнәсәбәтен ничек белдерүен аңлый белү сәләтен үстерүгә игътибар ителә. Алга таба сүзне тоемларга һәм аңларга гына түгел, ә аның туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аера һәм сөйләмдә куллана белергә өйрәтү дә мөһим. Сөйләмнең иң әһәмиятле бер төре — телдән сөйләм үстерелә. Диалог һәм монолог белән (текстта сүзләрне билгеләү, рольләргә бүленеп уку, укылган әсәр (текст) буенча кара-каршы сөйләшү) гамәли таныштырыла. Әдәби әсәргә һәм геройларга, аларның эш-гамәлләренә карата укучыларның үз мөнәсәбәте белдерелә. Әсәрнең эчтәлеген сөйләү, шигырьләрне һәм чәчмә әсәрләрдән кечкенә өзекләрне яттан сөйләү оештырыла.

**Иҗади эшчәнлек үсеше**

Укучыларда тиешле әдәби үсеш булдыруга, сәнгатьле итеп укырга һәм укыганны аңларга өйрәтүгә аларны мөстәкыйль иҗади эшчәнлеккә җәлеп иткәндә генә ирешергә мөмкин.

Әсәр белән эшләгәндә, геройларга укучыларның үз мөнәсәбәтен белдерү, үзенчә текстны үзгәртү кебек эш төрләре кертү мөһим. Бу эш төрләре, үз чиратында, укучыларда сөйләмгә иҗади элементлар кертү теләге тудыра.

Әдәби уку дәресләрендә түбәндәге метод һәм алымнар: ком- ментарияләү, интерпретация, форма һәм эчтәлекне анализлау, сәнгатьле уку һәм әсәрне сәхнәләштерү зур әһәмияткә ия. Әдәби уку дәресләрендә укылган әсәрләр буенча дәфтәрдә башкарыла торган эш төрләре (сүзләрнең асларына сызу, сүзләрне билгеләү, төркемнәргә туплау); иҗади эшчәнлек (рәсем ясау, буяу, китап тышлыкларын бизәү); уен алымнары (кроссворд, әдәби дидактик уеннар) һәм шулай ук төрле формадагы телдән (сурәтләү, чагыштыру характеристикалары, эчтәлек сөйләү, китапка бәяләмә бирү) һәм язма (фикерне язып бетерү, күчереп язу, сочинение язу) сөйләм кулланыла.

**Курс эчтәлеге**

**1—4 нче сыйныфларда** өйрәнелә торган материал тематик принципка нигезләнә, әдәби жанр һәм авторлар турында мәгълүмат бирелә.

Дәреслеккә, халык авыз иҗаты әсәрләре белән беррәттән, балалар язучыларының иң яхшы әсәрләре кертелде.

Программага әсәрне эмоциональ-эстетик яктан үзләштерү һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү принцибы салынган. Әдәби әсәрләр тәэсирендә туган әхлакый-эстетик кичерешләр кешенең дөньяга карашын формалаштыруда зур роль уйный. Яшь буынның хис-тойгыларына тәэсир итеп, матур әдәбият һәм фольклор әсәрләре югары кешелеклелек үрнәкләре аша яңа идеаллар тудыралар, уңай геройларга охшау омтылышы, әхлак нормалары һәм зәвык тәрбиялиләр, акыл эшчәнлегенә, танып белү үсешенә ярдәм итәләр. Югарыда әйтелгән принциплардан тыш, укыту процессының гомумпедагогик принциплары: системалылык, дәвамчанлык һәм перспективалылык та истә тотыла.

**1—4 нче сыйныфларда** укырга өйрәтү процессы ничек тормышка ашырыла соң**? 1 нче сыйныф** башында грамотага өйрәтү дәресләрендә балалар укырга өйрәнәләр, әдәби әсәрләрне тыңлап, зиһенгә кабул итәләр. Икенче яртыеллыкта балалар китаплары аша әдәби төшенчәләр (жанр, тема, автор, әсәр исеме, әкият, шигырь, әсәр) турында башлангыч күзаллау алалар.

**2 нче сыйныф**та инде тулы сүзләр белән укырга өйрәнәләр, укылган әсәрнең эчтәлеген аңлый, үзләренә аңлаешлы жанрны, авторларның исемнәрен, китап авторларын һәм әсәрләрне аера беләләр.

**3 нче сыйныф**та китап укучы шәхесен формалаштыру катлаулырак текстлар өстендә эшләү нәтиҗәсендә дәвам итә, укучының әдәбиятны танып белү эшчәнлеге тирәнәя, китап уку тәҗрибәсе байый.

**4 нче сыйныф**та китап уку тирәлеге киңәя, яңа авторлар, яңа жанрлар белән таныштырыла. Әсәрләр буенча башкарыла торган эш төрләре катлауландырыла.

## «ӘДӘБИ УКУ» КУРСЫН ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ 1 НЧЕ СЫЙНЫФ

**Грамотага өйрәтү чорыннан соң әдәби уку дәресләре башлана. Әдәби уку дәресләренә атнага 1 сәгать исәбеннән якынча 33 сәгать вакыт бирелә.**

### Сөйләм һәм китап уку эшчәнлеге төрләре

**Тыңлау (аудирование).** Әдәби әсәрне тыңлап кабул итү. Фольклор һәм әдәби әсәрләрне тыңлап зиһенгә кабул итә белү. «Ошый — ошамый» дигән фикерне дәлилләү. Геройларның эмоциональ хәләтен (шат, моңсу, гаҗәпләнгән һ.б.), эш-гамәлләрен, үз-үзләрен тотышларын чагыштыру һәм бәяләү. Төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне (шигырь, хикәя, әкият, кече фольклор әсәрләрен) тану.

**Уку.** Укучыларның шәхси мөмкинлекләреннән чыгып, иҗекләп һәм бөтен сүзләр белән, өзмичә, йөгерек уку. Тыныш билгеләренә карап, интонация белән сәнгатьле итеп уку. Зур булмаган шигырьләрне яттан сөйләү.

**Текст белән эш.** Җөмләләр җыелмасыннан текстны гамәли аера белү. Укытучы җитәкчелегендә, текстның мәгънәле кисәкләрен, абзацларны билгеләү. Текст төзелешен: башын, ахырын, вакыйгалар эзлеклелеген билгели белү. Текстка исем кую. Укытучы җитәкчелегендә схематик яки рәсемле план төзү.

### Универсаль уку гамәлләре (УУГ)

- төрле жанрдагы тыңланган һәм укылган әсәрләрне зиһенгә кабул итү (үзләштерү), әдәби сүз, укытучы һәм сыйныфташларның сөйләмен тыңлау һәм ишетеп кабул итү;
- тиешле күләмдәге әсәр текстларын аңлап һәм сәнгатьле уку;
- уку бурычын аңлау;
- әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү;
- уңай һәм тискәре геройларны аера белү;
- уку гамәлләре алгоритмын үзләштерү (сәнгатьле укырга әзерләнү, яттан сөйләү, рольләргә бүленеп уку, кыскартып яки тулысынча әсәр эчтәлеген сөйләү, геройларга, әсәргә, китапка бәяләмә бирү);
- төрле коммуникатив бурычларны истә тотып фикер йөртү;
- китапның исеменә, эчтәлегенә нигезләнеп эш итү, әсәрнең темасын, жанрын билгеләү;
- үз туган халкыңның һәм туган илеңнең үткәнен аңлау;
- бишек җыры, такмак, санамыш, мәкаль, табышмак, әкият, шигырь, хикәя җанрларын аера белү;
- жанры, темасы, авторлары буенча әсәрләрне чагыштыру;

• укыганчы ук әсәр һәм китапның эчтәлеген ачыклау (прогнозлау), авторның исем-фамилиясен, әсәрнең исемен билгеләү, тема һәм жанр төрен билгеләү.

**Уку тирәлеге**

Татар халык авыз иҗаты әсәрләре, 20 нче гасыр балалар язучыларының туган ил, балалар, табигать, хайваннар, кошлар, гаилә, кешелеклелек турында язылган әсәрләре.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• фольклор әсәрләрен жанры буенча танып белү;
• модельләштерү ярдәмендә әдәби төшенчәләрне үзләштерү;
• өйрәнелгән төшенчәләрне сөйләмдә куллану.

**Әдәби әсәрләр нигезендә укучыларның иҗади эшчәнлеге**

Сүз сәнгатенә кызыксыну уяту, күмәкләшеп, кечкенә әкият, хикәя төзүдә катнашу. Кечкенә күләмле әсәрләрне уйнап карау (сәхнәләштерү), рольләргә бүленеп уку; театрлаштырылган уеннарда катнашу. Әдәби геройлар турында вакыйгалар уйлап чыгару; кечкенә әкият яки хикәя эчтәлеген герой исеменнән сөйләү.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• әдәби бурычны аңлау һәм формалаштыру;
• әкият һәм хикәяләрне сәхнәләштерү;
• укылган әсәр геройлары катнашы белән төрле вакыйгалар уйлап чыгару.

**Уку: мәгълүмат белән эшләү**

Китапның тышкы билгеләре һәм иллюстрацияләре буенча мәгълүмат туплау.

Схема һәм таблица. Таблицадагы белешмәне уку, укытучы җитәкчелегендә әсәр һәм китап турындагы мәгълүматны таблицага язу.

**Грамотага өйрәтү чоры (8 сәгать) + Әдәби уку дәресләрен якынча тематик планлаштыру (25 сәгать)**

**Балачакта алган белем — ташка язган сүз белән бер (1 сәгать)**

Ибраһим Гази. Китап. Җәвад Тәрҗеманов. Китап.

**Бишектәге бишкә төрләнер (4 сәгать)**

Бишек җырлары. Тел шомарткычлар. Такмаклар. Санамышлар.

Әйтем — сүзнең бизәге, Мәкаль — сүзнең җиләге. Табышмак — зиһен ачкычы, Мәзәк — күңел ачкычы.

Алдавыч әкиятләр. Татар халык әкиятләре. Шүрәле. Ахмак бүре.

Карга ни өчен исемен әйтеп бетерми? (Башкорт халык әкияте).

**Хәреф миңа карап тора, мин дә карыйм хәрефкә... (5 сәгать)**

Габдулла Тукай. Әлифба. Зәкия Туфайлова. Әлифбам. Дәрдемәнд. Балалар, әйдә мәктәпкә!

Резеда Вәлиева. Беренчеләр. Роберт Миңнуллин. Ата-ана. Роберт Миңнуллин. Кояш.

Эльмира Шәрифуллина. Үзең күргәч. Хәкимҗан Халиков. Сакаллы малай.

Рәшит Бәшәр. Танышу. Шамил Маннап. Ат ник көлә?

Шәйхи Маннур. Яхшы бел. Йолдыз Шәрәпова. Белми. Шәүкәт Галиев. Витаминлы хәрефләр.

**Без хайваннар һәм кошлар турында беләбезме? (5 сәгать)**

Габдулла Тукай. Гали белән кәҗә. Габдулла Тукай. Карлыгач. Габдулла Тукай. Бала белән Күбәләк.

Резеда Вәлиева. Күбәләк һәм Кырмыска. Шәүкәт Галиев. Танышмак өчен табышмак.

Рабит Батулла. Әйлән-бәйлән уены. Рабит Батулла. Аю Әппәс. Рабит Батулла. Иң-иң-иң.

Габделхәй Сабитов. Балага — балык. Хәкимҗан Халиков. Укытучыларым.

Җәвад Тәрҗеманов. Табигать китабы. Эдуард Мостафин. Ат.

**Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен (5 сәгать)**

Дэрдемәнд. Гали. Җәвад Тәрҗеманов. Биш чия.

Идрис Туктар. Өлгер. Ләбиб Лерон. Супермалай.

Фәнис Яруллин. Хикмәтле сүз. Резеда. Вәлиева. Дуслык.

Гөлшат Зәйнашева. Бер атнада ничә көн? Шәүкәт Галиев. Светофорның өч күзе.

Тәүфикъ Әйди. Дачада. Ринат Мәннан. Булышам.

**Яз килә, яз килә... (5 сәгать)**

Габдулла Тукай. Яз. Бари Рәхмәт. Яз килә.

Гариф Галиев. Кояш. Гарәфи Хәсәнов. Ел язга аяк атлады.

Габделхәй Сабитов. Кояшка да эш күбәйде. Ләбиб Лерон. Апрель ае.

Гөлшат Зәйнашева. Әниләр бәйрәме. Резеда Вәлиева. Әниләр бәйрәме.

Роза Хафизова. Нәүрүз килә. Энҗе Мөэминова. Моңсу бәйрәм.

## 2 НЧЕ СЫЙНЫФ

### Сөйләм һәм китап уку эшчәнлеге

**Тыңлау (аудирование).** Әдәби әсәрне зиһенгә алу. Ишеткән сөйләмне кабул итү. Әңгәмәдәшеңнең фикерләрен, төрле текстларны укыганны тыңлый белү. Сөйләм барышында әйтелгән фикерне аңлау, ишеткән әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү. Бер үк һәм төрле әсәрләрнең персонажларын чагыштыру; әдәби әсәргә һәм персонажларга карата үз мөнәсәбәтеңне белдерү. Авторның үз геройларына булган мөнәсәбәтен ачыклау.

**Уку.** Кычкырып уку. Күләме зур булмаган текстларны, татар теленең үзенчәлекле авазларын дөрес әйтеп, иҗекләп укудан, әкренләп, йөгерек, аңлап, сүзләп укуга күчү.

Зур булмаган текстларны яки әсәр өзекләрен укыганда, эчтән укырга өйрәтү. Уку тизлеген даими арттыра бару. Укыганда, орфоэпик һәм интонацион нормаларны саклап, сәнгатьле итеп укырга өйрәтү. Уку эшчәнлеге буенча үзконтроль һәм үзбәяләү күнекмәләрен формалаштыру.

**Текст белән эш.** Текстта кулланылган сүз һәм сүзтезмәләрне аңлау. Күпмәгънәлелек очракларын аеру, чагыштыруларны билгеләү. Текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү һәм укытучы җитәкчелегендә гади план төзү; укытучы ярдәме белән әсәрнең төп уен билгеләү. Әзер план буенча әсәр эчтәлеген сөйләү; текст буенча сорау һәм биремнәрне мөстәкыйль үтәү.

### Универсаль уку гамәлләре (УУГ)

• тыңланган һәм укылган әсәрне зиһенгә кабул итү;

• 1 — 2 битле балалар китабы һәм зур булмаган әсәрләрне мөстәкыйль уку;

• кычкырып, эчтән, сәнгатьле уку күнекмәләрен үзләштерү;

• уку ролен аңлау һәм коммуникатив бурычларны хәл итү өчен файдалану;

• әдәби әсәр геройларының үз-үзләрен тотү үрнәгендә рухи-әхлакый, эстетик һәм мораль-эстетик кыйммәтләрне һәм идеалларны аңлау;

• уку бурычын аңлау, аны чишү юлларын билгеләү;

• төрле жанрдагы әсәрләрне анализлау (темасын билгеләү, әсәрнең төп уен аңлау, текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү һәм план төзү);

• китапның исеме һәм бизәлешенә карап, якынча темасын билгеләү;

• уңай һәм тискәре геройларны билгеләү (аерып алу), әсәр геройларын чагыштыру;

• текст буенча сорауларга җавап бирү;

• әсәр, геройлар турында үз фикереңне формалаштыру;

• куелган уку бурычы буенча эш-гамәлләрне планлаштыру (сәнгатьле уку, яттан һәм рольләргә бүленеп уку, әсәрнең эчтәлеген тулы итеп сөйләү) һәм бурычның үтәлү этапларын контрольдә тоту;

• китапларны тема, жанр һәм авторы буенча төркемләү;

• сүз мәгънәләрен аңлату, тексттагы сүзләрнең синонимнарын табу, сүзнең туры һәм контексттагы мәгънәләрен чагыштыру;

• жанр, тема, авторы буенча әсәрләрне чагыштыру.

**Уку тирәлеге**

Татар халкы һәм башка халык фольклоры әсәрләре: табышмак, санамыш, мәкаль, җыр, риваять, мәзәк, әкият. Татар балалар язучылары һәм шагыйрьләре, рус һәм чит халык авторлары әсәрләре. Фәнни-популяр әсәр, әкият, хикәя, шигырь жанрлары.

**Үрнәк тематика**

Туган ил, мәктәп, туган табигать, кеше һәм аның башкаларга мөнәсәбәте, балалар тормышы, дуслык, яхшылык турында.

**Библиографик культура**

Китап белән эш. Китап элементлары: китап тышлыгы, титул бите, бүлек һәм эчтәлек исемлеге, иллюстрация. Китап төрен билгеләү: әсәр, җыентык, сайланма әсәрләр, вакытлы матбугат (балалар журналы яки газетасы); автор турында белешмә, әсәр язылган чор турында мәгълүмат туплау.

**Әдәби пропедевтика**

Әдәби төшенчәләрне аңлау: әдәби әсәр, фольклор әсәрләре, халык әкияте, шигырь, хикәя, көнкүреш әкияте, хайваннар турындагы әкият, тылсымлы әкият, уйдырма, мәзәк, тизәйткеч, әдәби әсәр герое, реаль һәм уйдырма вакыйгалар, әсәр исеме, авторның исем-фамилиясе, диалог, рифма, чагыштыру, сынландыру (җанландыру). Белешмә.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• әдәби төшенчәләрне үзләштерү;

• тема буенча табышмак һәм мәкальләрне төркемләү;

• өйрәнелә торган әсәрне тема һәм жанры буенча бәяләү (характерлау);

• әдәби төшенчәләрне сөйләмдә куллану (жанр, тема, диалог, әсәр авторы, әсәр герое).

**Укучыларның иҗади эшчәнлеге**

Сүз сәнгатенә кызыксыну уяну. Кечкенә күләмле әкият һәм хикәяләр уйлап чыгаруда катнашу. Әсәр персонажларының берсе исеменнән әкиятне сөйләү. Әкият, хикәя эчтәлеген дәвам итү, башын һәм ахырын үзгәртү. Иҗади-коллектив эшләр: «Әкият геройлары» темасына проектлар, дәрес-әкият, дәрес-тамаша, дәрес-конкурс, дәрес-уен һ.б. әзерләү һәм үткәрү.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• автор позициясен аңлау һәм сәнгатьле уку, иҗади сөйләү аша үз мөнәсәбәтеңне белдерү;

• рольләргә бүленеп сәнгатьле итеп уку, зур булмаган текстларны яки аерым эпизодларны сәхнәләштерү;

• әсәрдә катнашучы геройлар турында кызыклы вакыйгалар уйлап чыгару.

**Уку: Уку материалы белән эш**

Белешмә: китап, әсәр, әсәр авторы, жанр, тема.

Китап аппаратына (титул бите, аннотация, кереш сүз, «Автор турында», «Автордан» рубрикалары) таянып, мәгълүмат туплау. Герой исемнәре, геройларның эш-гамәлләре, автор позициясе, укучы фикере турында таблицалар төзү. Укыганда, герой һәм әсәргә бәяләмә биргәндә, таблицада язылган мәгълүматтан файдалану. Автор, жанр, тема һәм китап төрләре турында мәгълүмат булган таблицаларны тулыландыру.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• геройлар, аларның эш-гамәлләре, әсәр яки китаплар турындагы кирәкле мәгълүматны эзләп табу һәм билгеләү;

• өйрәнелә торган әсәр эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга сыйныфташларның җавабын тыңлау, ул җавапларны тулыландыру һәм ачыклау, фикерләрне әсәрдән алынган мәгълүмат белән дәлилләү;

• текстта бирелгән мәгълүматны аңлау һәм шуның нигезендә таблица яки схемаларда җитешмәгән мәгълүматны тулыландыру.

**Предметара бәйләнеш**

• татар теле дәресләре белән: геройлар турында җөмләләр, мини текстлар уйлап язу;

• рәсем дәресләре белән: аерым әсәрләрне иллюстрацияләү, иҗади эшләрне бизәү, әсәр эчтәлеге буенча оештырылган рәсем күргәзмәләрендә катнашу, сынлы сәнгать музее рубрикасы аша рәсем сәнгате һәм рәссамнар иҗаты белән танышу;

• технология дәресләре белән: кечкенә күләмле китапчыклар төзү, китапларны төпләү, китап элементлары белән гамәли танышу, күмәк иҗат дәресләре (аппликация) үткәрү.

**Әдәби уку дәресләрен якынча тематик планлаштыру (34 сәгать)**

**Туган ил ул бер генә, чәчәк кенә, гөл генә (4 сәгать)**

Габдулла Тукай. Туган тел. Зәкия Туфайлова. Туган ил.

Резеда Вәлиева. Туган җир. Гариф Галиев. Туган ил кайдан башлана?

Минем республикам

Ринат Мәннан. Татарстан флагы. Газинур Морат. Иң матур ил.

Казан кайнаган урын. (Риваять). Шәһәр нигә Казан дип аталган? (Риваять). Резеда Вәлиева. Казаным, минем Казаным.

**Халык әйтсә — хак әйтә (3 сәгать)**
Әпипә. Матур булсын. (Халык җыры).
Табышмаклар. Санамышлар. Мәзәкләр. Мәкальләр.
Әкиятләр. Хәйләгә каршы хәйлә. (Татар халык әкияте).
**Алтын көз килә туган илемә (4 сәгать)**
Габдулла Тукай. Көз.
Мөҗәһит Әхмәтҗанов. Көз.
Гариф Галиевтан. Айлар алышынганда. Николай Сладковтан. Көз җитте.
**Балачак мизгелләре (4 сәгать)**
Йолдыз Шәрәпова. Тылсымлы сүзләр. Әминә Бикчәнтәева. Тәмле сүз.
Шәүкәт Галиев. Рәхмәтләр хакында.
Рафис Гыйззәтуллин. Тылсымлы сүз. Нәкыйп Каштанов. Ачулы туп.
**Ап-ак карлар яуганда (4 сәгать)**
Шәехзадә Бабич. Кышкы юл. Роберт Миңнуллин. Ак кыш. Галимҗан Ибраһимовтан. Кар ява.
Госман Бакир. Кышкы уен. Җәүдәт Дәрзаман. Җепшек көндә. Зиннур Хөснияр. Кышкы урман табышмаклары.
Гәрәй Рәхим. Безнең тауда. Шәриф Биккол. Урман читендә.
Яңа ел килгәндә
Рафис Корбан. Чыршы бәйрәме. Җәвад Тәрҗеманов. Һай, Кыш бабай...
**Яраткан кошларыбыз һәм хайваннарыбыз (4 сәгать)**
Гакыйль Сәгыйрев. Акбай. Резеда Вәлиева. Ак песи. Мәхмүт Хөсәен. Безнең дусларыбыз.
Әнәс Кари. Тиен. Рабит Батулла. Куян баласы Нуяк. Муса, Җәлил. Күке.
Зиннур Хөснияр. Тукран тәүбәсе. Әминә Бикчәнтәева. Үрдәк беренчелекне алган. Шәүкәт Галиев. Колынкаем.
Кем нәрсә ярата. (Татар халык әкияте). Тавык, Тычкан һәм Көртлек. (Татар халык әкияте). Итагатьле мәче. (Литва халкы әкияте). Комсызлык бәласе. (Венгр халкы әкияте). Юмарт Дөя. (Казах халкы әкияте).
**Яз килә, яз көлә... (4 сәгать)**
Әминә Бикчәнтәева. Апрель ае. Марс Шабаев. Ташу. Роберт Миңнуллин. Яз керде өебезгә.
Гасыйм Лотфи. Сыерчык. Гәрәй Рәхим.. Каргалар шәһәре. Зәкәрия Әхмәров. Агачлар да авырый.
Рафис Корбан. Җиңү бәйрәме. Хәкимҗан Халиков. Рәхмәт сезгә, ветераннар!
Рафис Гыйззәтуллин. Миләш нигә әче?
**Тату гаилә (4 сәгать)**
Габдулла Тукай. Безнең гаилә. Илдар Юзеев. Һәркемнең үз эше.
Бикә Рәхимова. Бишек җыры. Зоя Воскресенская. Әни. Клара Булатова. Әниемнең кызы юк бит.
Галимҗан Гыйльманов. Чәчәк буласым килә. Рөстәм Мингалим. Канатларың булса. Илдар Юзеев. Дәү әнием.
Роберт Миңнуллин. Улы белән әнисе. Әхмәт Исхак. Ана рәхмәте. Бертуган Якоб һәм Вилъгелъм Гриммнар. Боткалы чүлмәк.
**Җиләкле җәй (3 сәгать)**
Җәүдәт Дәрзаман. Саумы, җәй. Шәүкәт Галиев. Тәмле җәй.

Бари Рәхмәт. Иң күңелле чак. Ләбиб Лерон. Җәйге бәхәс.
Эльмира Шәрифуллина. Сабантуй. Рафис Корбан. Кояш — безнең дустыбыз.

**3 НЧЕ СЫЙНЫФ**

**Сөйләм һәм уку эшчәнлеге төрләре**

**Тыңлау (аудирование).** Әдәби әсәрләрне үзләштерү (зиһенгә алу). Төрле жанрдагы әсәрләрне үзләштерү, төп фикерне (уйны) аңлау.

Бер жанрдагы әсәрләрне яисә бер үк авторның әсәрләрен чагыштыру, әсәрнең үзенчәлеклекләрен (текст композициясен, әсәрнең телен, геройлар бирелешен) өйрәнү. Төрле әсәр геройларын чагыштыру, аларның эш-гамәлләрен анализлау, бәяләү өчен кирәкле детальләрне аерып алу, вакыйгалар булган урын һәм вакытны билгеләү, герой портретын сурәтләгән урыннарны билгеләү. Автор позициясен ачыклау һәм әсәргә, геройларга үз мөнәсәбәтеңне булдыру (формалаштыру).

**Уку.** Зур булмаган әсәрләрне яки әсәр бүлекләрен кычкырып һәм эчтән уку. Вакыйгаларга һәм геройларга үз мөнәсәбәтеңне белдереп, әсәр текстын сәнгатьле итеп уку.

**Текст белән эш.** Вакыйгалар эзлеклелегенә һәм мәгънәсенә төшенү. Текстның төп уен ачыклау. Геройның эш-гамәлләре һәм аларның мотивларын билгеләү, анализлау, чагыштыру. Әсәрдә катнашучыларны, вакыйгаларны характерлаучы сүз һәм тәгъбирләрне табу, автор позициясен һәм вакыйгаларга, персонажларга (әсәрдә катнашучыларга) карата үз мөнәсәбәтеңне белдерү.

**Текст төзелеше белән эш.** Башлам, үсеш, бетем; текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү һәм аларга исем кую; укытучы җитәкчелегендә план төзү. Әзер план буенча текст эчтәлеген тулысынча яки кыскача сөйләү. Текст буенча бирелгән биремнәрне мөстәкыйль үтәү.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• уку ролен аңлау; танып белү һәм коммуникатив бурычларны үтәү өчен, укый белү күнекмәсеннән файдалану;

• уку бурычын аңлый һәм куя белү, бу бурычны үтәү алымнарын билгеләү, үзэшчәнлек нәтиҗәләрен үрнәк буенча чагыштырып, үзконтроль һәм үзбәя үткәрү, төгәлсезлекләр һәм хаталарны табу, үзэшчәнлек нәтиҗәләре буенча өстәмәләр һәм төзәтүләр кертү;

• уку бурычыннан чыгып, уку төрен (танышу максатыннан яки беренчел, өйрәнү максатыннан, эзләнү яки карап чыгу максатыннан) билгеләү;

• укыганда һәм тыңлаганда, төрле төрдәге текст эчтәлеген үзләштерү (темасын билгеләү, әсәрнең төп уен аңлау, текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү һәм план төзү, автор уен аңлау, эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү);

• әсәр, герой һәм аларның кыланышлары, эш-гамәлләре турында план төзегәндә, төп һәм өстәмә мәгълүматларны (информацияне) билгеләү;

• эчтәлек сөйләүнең төрле төрләрен кулланып, укылган һәм тыңланган әсәрнең спецификасын саклап, эчтәлекне сөйләү;

• сүз мәгънәләрен аңлату, әсәрдәге сүзләрнең синонимнарын табу, сүзләрнең туры һәм контексттагы мәгънәләрен чагыштыру;

• әдәби әсәр геройларының эш-гамәлләре үрнәгендә, рухи- әхлакый, эстетик, мораль-эстетик кыйммәтләрне үзләштерү; әдәби әсәрне анализлаганда, автор позициясен аңлату һәм үз фикереңне белдерү;

• фикерне ирекле формада әйтү һәм дәлилле итеп төзү, нинди тыңлаучы булуын исәпкә алып һәм сөйләү максатын истә тотып, фикерне тулы һәм төгәл итеп белдерү;

• әңгәмәдәшнең фикеренә ихтирам белән карап, әсәр, геройлар һәм аларның эш-гамәлләре турында оештырылган диалог яки дискуссиядә (сөйләшүдә) катнашу;

• геройларның эш-гамәл мотивын билгеләү, әхлак кагыйдәләре нормаларыннан чыгып, аларның эш-гамәлләренә бәя бирү;

• әсәрләрне һәм китапларны темасы, жанры, авторга мөнәсәбәте буенча төркемләү.

**Уку тирәлеге**

Халык авыз иҗаты әсәрләре. Татар шагыйрьләре һәм язучыларының шигъри һәм чәчмә әсәрләре. Әдәби һәм фәнни-популяр мәкаләләр.

**Үрнәк тематика**

Туган як табигате, туган ил, туган җир, гаиләдә туганлык мөнәсәбәте, әхлакый сыйфатлар, спорт турындагы әсәрләр.

**Жанр төрлелеге**

1 — 2 нче сыйныфтагыларга караганда катлаулырак әкият, хикәя, мәсәл, шигъри әсәрләр.

Халык әкиятләре: кабатлаулар, яхшылыкның яманлыктан өстенлеге. Реаль һәм уйдырма вакыйгалар. Уңай һәм тискәре геройлар.

Әдәби хикәяләр: вакыйга һәм геройлар сурәтләнеше, диалогик сөйләм өстенлеге, эпитет, чагыштыру, сынландыру (җанландыру) кулланылышы.

**Әдәби төшенчәләр (пропедевтика)**

Әдәби төшенчәләрдә ориентлашу: әдәбият, фольклор, әдәби әсәр. Әдәби жанрлар: әкият, мәсәл, мәкаль, табышмак, әйтем, санамыш.

Диалог, фәнни-популяр очерк, герой (персонаж), герой портреты, пейзаж, шигырь, рифма, строфа, дүртьюллык. Сәнгатьлелек чаралары: логик пауза, темп, пауза.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• фольклор һәм автор әсәрләрен чагыштыру, аларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү;

• чәчмә әсәрне — шигъри, фәнни-популяр әсәрне әдәби әсәрдән аера белү;

• кече фольклор жанр әсәрләрен төзелешләре ягыннан чагыштыру; әдәби төшенчәләрне сөйләмдә куллану.

**Укучыларның иҗади эшчәнлеге**

Әдәби сүзгә карата кызыксыну үстерү. Табышмак, мәзәк, әкият, әсәр геройлары турында кызыклы хәлләр уйлау. Күмәк иҗади эшләр: әдәби уен, конкурс, кичәләр үткәрү.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• мөстәкыйль иҗади эшчәнлек бурычын аңлау һәм формалаштыру;

• уку эшчәнлеген мәгълүмат алу һәм шәхси танып белү таләпләрен канәгатьләндерү чарасы буларак кабул итү;

• практик юнәлештәге биремнәрне үтәү, өйрәнелә торган тексттан кирәкле информацияне (мәгълүматны) табу; эчтәлек һәм тел үзенчәлекләрен бәяләү;

• әсәр текстында вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү һәм сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен анализлау;

• әсәр, геройлар һәм аларның эш-гамәлләре турында булган төп һәм өстәмә мәгълүматны билгеләү;

• текстта бирелгән информацияне аңлау, аның нигезендә таблица һәм схемалардагы җитешсезлекләрне тулыландыру;

• китапта ориентлашу (эчтәлек, кереш һәм йомгаклау сүзләреннән файдалану);

• яшь үзенчәлекләренә туры килгән сүзлек һәм белешмәлекләрдә ориентлашу.

**Предметара бәйләнеш**

• татар теле дәресләре белән: укылган әсәргә 2—3 җөмләдән торган аннотация (бәяләмә), персонаж һәм пейзажны сурәтләп язу, әкият, хикәя, санамыш уйлап язу;

• музыка дәресе белән: аерым җыр текстлары белән танышу;

• рәсем сәнгате белән: рәссамнар, иллюстрацияләр белән танышу;

• технология дәресе белән: кечкенә күләмле китапчыклар төзү, китапларны төпләү, китап элементлары белән гамәли танышу, күмәк иҗат дәресләре (аппликация) үткәрү.

**Әдәби уку дәресләрен якынча тематик планлаштыру (34 сәгать)**

**Сау бул, җәй, исәнме мәктәп! (4 сәгать)**

Разил Вәлиев. Сау бул, җәй! Мәҗит Гафури. Балалар эше. Мәҗит Гафури. Китап һәм балалар.

Вакыйф Нуриев. Китап. Габдулла Тукай. Кызыклы шәкерт. Хәкимҗан Халиков. Былбыл сайратам.

Газинур Морат. Туган тел. Рафис Гыйззәтуллин. Кечкенә Ринат.

Каюм, Насыйры. Акыллы һәм яхшы холыклы.

**Энҗе чәчтем, энҗе җыям (2 сәгать)**

Табышмак — зиһен ачкычы. Әкият эзләре буйлап.

Бүре, кәҗә, кәбестә. (Әкият-табышмак). Кем җиңүче? (Татар халык әкияте).

**Мәсәлләр (2 сәгать)**

Каюм Насыйры. Комсыз эт.

Габдулла Тукай. Умарта корты һәм чебеннәр. Габдулла Тукай. Өтәч белән Күке.

**Алтын сукмак буйлап көз атлый (3 сәгать)**

Илгизәр Солтан. Көз. Дания Гайнетдинова. Көзге урман. Фәнис Яруллин. Көзге табын.

Идрис Туктар. Урман букеты. Николай Сладков. Алтын көз.

Мәҗит Гафури. Хушыгыз, кыр казлары! Муса Җәлил. Уңыш бәйрәме.

**Туган ягым — алтын бишек (3 сәгать)**

Бари Рәхмәт. Алтын безнең җир. Рафис Корбан. Ватан.

Резеда Вәлиева. Иң матур җир. Сания Әхмәтҗанова. Казаным — башкалам. Ләбиб Лерон. Татар баласы. Гомәр Бәширов. Нинди ул Татарстан? Марс Шабаев. Идел суы.

**Кырга ак кардан юрган ябылган (3 сәгать)**

Фатих Хөсни. Беренче кар. Нәҗип Думави. Беренче кар. Виталий Бианки. Куян, Көртлек, Аю һәм Кыш бабай.

Габдулла. Тукай. Җир йокысы. Абдулла Әхмәт. Кышкы матурлык. Гасыйм Лотфи. Песнәк белән Әнисә.
Әхмәт Ерикәй. Кыш. Роберт Миңнуллин. Чыршы әйләнәсендә.

**Әдәпле кешеләр була һәрчак матур гадәтле (3 сәгать)**

Вәсимә Хәйруллина. Әдәп. Абдулла Әхмәт. Малайлар аңламадылар. Зәкәрия Әхмәров. Шулай да булгалый.
Әхсән Баян. Яхшылык кире кайта. Нәкыйп Каштанов. Йөнтәс песи баласы. Резеда Вәлиева. Яңа көрәк.
Рафис Гыйззәтуллин. Көтелмәгән сорау. Вәсимә Хәйруллина. Табын кагыйдәләре.

**Гаиләдә туганлык хисләре (4 сәгать)**

Әминә Бикчәнтәева. Әтием белән бергә. Резеда Вәлиева. Туган көндә.
Әнәс Хәсәнов. Сез ни әйтерсез икән? Абдулла Алиш. Утлы йомырка.
Дәрдемәнд. Богъдай. Рабит Батулла. Карурманга бара Мөбарәк.
Фәнис Яруллин. Кояштагы тап. Муса. Җәлил. Себерке әкияте.

**Яз бизәкләре (2 сәгать)**

Шәүкәт Галиев. Җиргә язны кем китерә? Дәрдемәнд. Кояш нурлары.
Вәсимә Хәйруллина. Яз килә. Гыйльмия Таһирова. Даниянең тополе.

**Без — әкият дуслары (3 сәгать)**

Марсель Галиев. Алып кит еракка. Гөлчәчәк. (Татар халык әкияте).
Соңгы бөртек. (Удмурт халкы әкияте). Тату туганнар. (Корея халкы әкияте). Габдулла Тукай. Су анасы. Абдулла Алиш. Чукмар белән Тукмар. Хәкимҗан Халиков. Мыекбай.

**Сәламәт тәндә — сәламәт акыл (2 сәгать)**

Йолдыз Шәрәпова. Татарстан — спорт иле. Хәкимҗан Халиков. Хәрәкәттә — бәрәкәт.
Сания Әхмәтҗанова. Үрнәк алыйк.

**Чәчәкле җәй (3 сәгать)**

Мәрзия Фәйзуллина. Җәй җитте. Габдулла Тукай. Яңгыр.
Галимҗан Ибраһимов. Җәйге көндә. Рәшит Бәшәр. Июнь.
Вахит Монасыйпов. Шифалы табиблар. Гариф Ахунов. Сабан туенда. Газинур Морат. Сабан туе.

## 4НЧЕ СЫЙНЫФ

### Сөйләм һәм китап уку эшчәнлеге

**Тыцлау (аудирование).** Әдәби әсәрне зиһенгә алу (үзләштерү). Әсәрне, эчтәлек һәм форма бердәмлеге, образ, логик һәм эмоциональ башлангыч берлеге буларак, тулысынча кабул итәргә, үзләштерергә шартлар булдыру.

Эмоциональ ярдәмчеллек, әдәби әсәр кәефен аңлау, геройларның кәефләрендәге охшашлык һәм каршылыкны (аерманы), автор карашын аңлау (төшенү). Әсәр эчтәлеген бәяләү. Геройларның эмоциональ халәтен, аларның эш-гамәлләрен, кыланышларын, эшләгән эшләрен анализлау. Төрле әсәр персонажларын чагыштыру, авторның аларга карата булган мөнәсәбәтен ачыклау, әсәр тексты белән дәлилләнгән фикерне белдерү.

Төрле жанрдагы әсәрләрне ишетеп кабул итү, персонажларны характерлаган сүзләрне, табигать сурәтен тудыручы, кешене сурәтләүче

тәгъбирләрне истә калдыру. Табигатьне, интерьер, портрет һәм герой сөйләмен сурәтләүнең ролен аңлау.

Уку бурычын билгели белү — нәрсә һәм нинди максат белән укыла, сөйләнә, хәбәр ителә. Әсәрне сәнгатьле уку чараларын: логик басым, пауза, тон, сөйләм темпын таба белү.

Әсәрдәге реаль һәм уйдырма күзаллауны чагыштыра белү.

**Уку.** Әдәби әйтелеш нормаларына туры китереп, аңлап, дөрес, сәнгатьле итеп уку.

**Әсәр белән эш.** Текст кисәкләре арасындагы мәгънә бәйләнешен билгеләү. Геройларның эш-гамәл мотивларын ачыклау һәм аларны бәяләү; геройларның эш-гамәлләрен, үз-үзләрен тотышларын чагыштыра белү; геройларның эш-гамәлләрен, табигать күренешен сурәтләүче сүз һәм тәгъбирләрне табу; тексттагы эпитет, чагыштыруларны табу.

Хикәя, әкиятнең гади планын төзү, план буенча әсәр эчтәлеген тулы итеп, кыскартып һәм сайлап алып сөйләү.

Эчтәлекне иҗади сөйләү (сөйләүче затны үзгәртеп, герой язмышлары турындагы хикәяне үз күзаллавыңча үзгәртеп дәвам итү, сүзле картина формасында текст эчтәлеген искә төшерү). Вакыйгаларга, геройларга һәм фактларга автор фикерен һәм үз фикереңне ачыклау.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• танып белү һәм коммуникатив бурычны чишү өчен, укый белү күнекмәсен файдалану, куллану;

• уку бурычын аңлый һәм куя белү, ул бурычны үтәү ысулларын билгеләү һәм иң продуктив ысулны сайлап алу;

• типик уку бурычларын үтәү алгоритмын үзләштерү (рольләргә бүленеп уку, сәнгатьле уку, яттан уку, тулы итеп һәм сайлап алып эчтәлекне сөйләү), алгоритм буенча биремнәр үтәлешен тикшерү, яңа бурычлар өчен алгоритм төзү;

• куелган максатлардан чыгып, уку төрен (танышу максаты яки беренчел, өйрәнү максаты, эзләнү максаты, карап чыгу максаты, сәнгатьле уку максатыннан) билгеләү;

• төрле жанрдагы әсәр текстлары белән эшли белү: теманы билгеләү, әсәрнең төп уен аңлау, текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, план төзү, автор уен аңлау, эчтәлек буенча сорауларга җавап бирү;

• план төзү, вакыйгалар эзлеклелеген һәм алар арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен билгеләү;

• язма һәм телдән сөйләм коммуникатив культурасын үзләштерү; диалогик һәм монологик сөйләм төзү; укылган һәм тыңланган әсәр һәм китаплар турында фикерләр әйтү, әңгәмәдәшнең фикерен тыңлау, башкаларның фикеренә ихтирам белән карау, сорауларга язма җаваплар формалаштыру, әсәргә бәяләмә язу;

• үзконтроль һәм үзбәя үткәрү; үрнәк белән үз фикереңне чагыштырып, төгәлсезлекләр һәм хаталарны мөстәкыйль таба белү, үзгәртүләр, өстәлмәләр, төзәтүләр кертү, үз эшчәнлегеңне бәяләү;

• уку бурычыннан чыгып, үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп җиткерә белү, ирекле һәм дәлилле фикерләр төзү (әйтү);

• укыр алдыннан, авторның исем-фамилиясен, эчтәлек исемлеге, тема һәм жанры буенча әсәр һәм китапның эчтәлеген алдан билгели алу осталыгы булдыру;

• әсәрне анализлау үрнәгендә автор позициясен аңлау һәм үз фикереңне белдерү;

• сүз сәнгате буларак әдәби әсәрне кабул итү, әсәрнең эстетик кыйммәтен аңлау һәм аның нигезендә үзеңдә эстетик критерийлар булдыру;

• текстны ишетеп аңларлык тизлектә кычкырып һәм эчтән уку, төрле уку төрләреннән (танышу яки өйрәнү максатыннан, эзләнү яки карап чыгу максатыннан) файдалану;

• әдәби геройларның эш-гамәлләрен анализлау һәм бәяләү аша үз-үзеңне тотуның мораль-эстетик нормаларын үзләштерү;

• әдәби әсәрнең әхлакый эчтәлегендә ориентлашу, геройларның эш-гамәлләренең асылына төшенү, аларга бәя бирү;

• әдәби геройлар һәм үзеңне чагыштыру юлы аша камиллеккә, үзбилгеләнешкә һәм үзбелемгә омтылу.

**Уку тирәлеге**

Татар һәм башка милләт балалар язучыларының шигъри һәм чәчмә әсәрләре. Маҗаралы балалар китабы. Табигать, тарихи һәм фәнни ачышлар турында фәнни-популяр мәкаләләр. Юмористик һәм сатирик әсәрләр.

Белешмә балалар әдәбияты (балалар энциклопедиясе, сүзлекләр).

**Якынча тематика**

Балалар тормышы турында, туган ил һәм башка илләр, хезмәт һәм иҗат, сәяхәт һәм маҗаралар турында әсәрләр. Фәнни-танып белү әсәрләре: үсемлек һәм хайваннар турында фәнни-популяр мәкаләләр.

**Жанр төрлелеге**

Балаларның жанр үзенчәлекләре турында булган белемнәрен үстерү (киңәйтү), халык һәм автор әкиятләре, шигъри һәм чәчмә (хикәя, очерк, мәкалә) әсәрләр. Әдәби әсәр һәм фәнни-популяр мәкаләләрне, авторларның төрле жанрдагы әсәрләрен чагыштыру.

**Хикәяләр:** фәнни-популяр, әдәби хикәя үзенчәлекләре. Геройлар, алар тормышындагы вакыйгаларның эмоциональ-образлы, ягъни китап укучы баланың хыялын уятырлык итеп сурәтләнүе. Авторның геройларына карата булган мөнәсәбәте.

**Фәнни-популяр әсәрләр.** Үзенчәлекләре: образның төшенчә һәм терминнан аермасы, логик бәйләнеш үсеше, «фактлар теле», төп фикер, нәтиҗә, дөрес фикри нәтиҗә чыгару.

**Очерк:** чынбарлыкта булган реаль вакыйгалар, кешеләр һәм аларның эшләре турында хикәяләү. Илдәге вакыйгалар, кешенең туган илгә, кешеләргә, табигатькә булган мөнәсәбәте белән танышу.

**Китап турында библиографик белешмә**

Китап элементлары: тышлык, титул бите, исеме, кереш сүз, соңгы сүз, аннотация, иллюстрацияләр. Каталог. Каталог карточкасы. Вакытлы матбугат (балалар газеталары һәм журналлары исемлеге).

Автор турында белешмә. Әсәр язылган чор турында башлангыч белем булдыру.

**Әдәби төшенчәләр (пропедевтика)**

Әдәби төшенчәләрне (әдәбият, фольклор, әдәби әсәр, әдәби иҗат) үзләштерү.

Әдәби жанрлар: бәет, мәсәл, риваять, хикәя, шигырь, әкият- пьеса, очерк, фәнни-популяр мәкалә, фәнни-әдәби әсәр.

Әсәр темасы, идеясе: әдәби герой, портрет, автор бәяләмәсе, сюжет, композиция.

Тел-сурәтләү чаралары: эпитет, чагыштыру, сынландыру (җанландыру), гипербола.

Автор уен белдерү чарасы буларак юмор һәм сатира.

Фантастика һәм чынбарлык.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• әдәби төшенчәләрне сөйләмдә куллану; әсәрдән сурәтләү чараларын (эпитет, чагыштыру, сынландыру (җанландыру), антоним, метафора, гипербола) табу;

• әдәби һәм фәнни-популяр текстларны аеру; шигъри һәм чәчмә әсәрләрне аеру;

• текст структурасы һәм китап аппаратында ориентлашу, китап төрен (китап-әсәр, китап-җыентык) билгеләү.

**Укучыларның иҗади эшчәнлеге**

Изложение, күләме зур булмаган сочинение яза белү. Таныш сюжетны «язып бетерү», «дәлилләү». Халык авыз иҗаты үрнәгендә табышмак, такмак, әкият, әйтем уйлау.

Укылган китапларга бәяләмә, аннотация язу, китапның каталог карточкасын төзү.

Зур булмаган әсәр сюжетларын сәхнәләштерү, сәхнәләштерелгән уеннарда, диалогларда катнашу.

**Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**

• текст эчтәлеген автор яки герой исеменнән сөйли һәм иҗади уку бурычын мөстәкыйль формалаштыра белү, бу бурычны үтәү ысулларын һәм формаларын сайлау (шәхси проект, парлап яки группада эшләү), конкурслар, китапханә дәресләре, музейда әдәби дәресләр оештыру һәм үткәрү;

• аналогия буенча төрле жанрдагы әсәрләр иҗат итү, бирелгән рифмалар буенча шигъри юллар уйлау, иҗади эш һәм проектлар презентациясен ясау һәм бизәү;

• мөстәкыйль иҗади уку бурычын аңлау һәм формалаштыру;

• коллектив иҗади проектлар эшләгәндә, эш һәм рольләрне бүлешү;

• текстны бер герой, автор яки үз исемеңнән сөйләү, текст эчтәлеге буенча бозылган планны төзәтү;

• әдәби әсәрләрне сәхнәләштерү.

**Предметара бәйләнеш**

• татар теле белән: әдәби әсәр геройлары турында телдән һәм язма хикәяләр, укылган әсәрләргә бәяләмә, сөйләмнең төп формаларын (сурәтләү, фикерләү, хикәяләү) куллана белү; әкият, хикәя, кызыклы вакыйгалар турында язу буенча беренчел тәҗрибә туплау;

• музыка дәресе белән: аерым җыр текстларының көе турында күзаллау булдыру;

• әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең уртаклыгы, китап иллюстрацияләре турында күзаллау булдыру; иллюстрация һәм текстны чагыштыру, рәссам күзаллавында әсәр чагылышын ачыклау.

**Әдәби уку дәресләрен якынча тематик планлаштыру (34 сәгать)**

**Халык сүзе алтындыр, аңлаганга акылдыр (7 сәгать)**

Җил арба. (Татар халык әкияте). Җил иясе. (Миф).

Тургай һәм Кояш. (Миф). Фатих Әмирхан. Ай өстендә Зөһрә кыз.

Сак-Сок. (Бәет).

Иван Крылов. Карга белән Төлке. (Габдулла Шамуков тәрҗемәсендә).

Мәҗит Гафури. Чикерткә белән Кырмыска. (Мәсәл). Мәҗит Гафури. Тавык белән Үрдәк. (Мәсәл).

Габдулла Тукай. Яшь Агач. (Мәсәл).

Әхмәт Исхак. Карт Имән белән яшь егет.

**Язучылар иҗатында табигать (7 сәгать)**

Габдулла Тукай. Ай һәм Кояш. Габдулла Тукай. Фатыйма белән Сандугач. Габдулла Тукай. Шүрәле. Мәҗит Гафури. Болын.

Муса Җәлил. Яңгыр. Муса Җәлил. Чишмә.

Абдулла Алиш. Койрыклар. Абдулла Алиш. Кемгә кирәк, кемгә кирәкми.

Нәби Дәүли. Бала болыт. Рәшит Бәшәр. Сандугачлы Ак инеш.

Гарәфи Хәсәнов. Кышкы урман. Фәнис Яруллин. Иң бәхетле төн.

Сания Әхмәтҗанова. Саклыйк, әйдә, Җир-ананы.

**Балачак әдипләре (7 сәгать)**

Шәүкәт Галиев. Камырша. Шәүкәт Галиев. Күршеләрнең алмасы.

Шәүкәт Галиев. Минем абый шигырь ятлый... Шәүкәт Галиев. Куркыныч хәбәр.

Роберт Миңнуллин. Әни, мин көчек күрдем. Роберт Миңнуллин. Спортның яңа төре.

Хәкимҗан Халиков. Дәү әти. Хәкимҗан Халиков. Вакыты тар.

Хәкимҗан Халиков. Чыпчык баласы Чырчыр турында әкият. Хәкимҗан Халиков. Нинди кош.

Фәнис Яруллин. Ап-ак иткән. Фәнис Яруллин. Бияләй.

Фәнис Яруллин. Юылмас хурлык.

**Яхшылык эшләргә ашыгыйк... (5 сәгать)**

Роза Хафизова. Күгәрчен һәм малай. Сәрвәр Әдһәтова. Дуслар.

Әхсән Баян. Эт янында тиеннәр.

Дәрҗия Аппакова. Шыгырдавыклы башмаклар.

Михаил Зощенко. Мескен Федя. Резеда Вәлиева. Җиңү көнендә.

**Бәхетле балачак (3 сәгать)**

Нәбирә Гыйматдинова. Сертотмас Кәҗә.

Виктор Голявкин. Әллә каян күренеп тора.

Юрий Ермолаев. Сәгать ярдәм итте.

**Серле дөнья, могҗизалы дөнья (5 сәгать)**

Ганс Христиан Андерсен. Чыдам кургашын солдат.

Джонатан Свифт. Гулливер сәяхәте.

Ләбиб Лерон. Шүрәле малае.

Зиннур Хөснияр. Шүрәле җыры.

**УКЫТУНЫҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ**

**1 нче сыйныф ахырында укучылар түбәндәге нәтиҗәләргә ирешә:**

**«Сөйләм һәм уку эшчәнлеге төрләре» юнәлеше буенча**

**укучы**

— фольклор әсәрләрен (такмак, җыр, санамыш, табышмак, мәкаль, әйтем, әкият) аңлап зиһенгә кабул итә һәм аера белергә;
— төрле жанрдагы (хикәя, шигырь, әкият) әсәрләрне кычкырып укырга һәм эчтәлек буенча сорауларга җавап бирергә;
— әдәби әсәрне дөрес итеп әйтергә (авторның исем-фамилиясе, әсәрнең исеме);
— китап тышлыгын модельләштерергә: авторын, исемен, жанрын һәм темасын (туган ил, балалар, хайваннар, табигать турында) **өйрәнә.**

**Укучыга:**

— укылган әсәрнең әхлакый эчтәлеген аңларга;
— әсәр һәм геройлар турында фикерләрен җиткерергә;
— әсәр өзекләреннән укылган әсәрләрне танырга **өйрәнергә мөмкинлек туа**.

**«Әдәби пропедевтика» юнәлеше буенча**

**укучы**

— өйрәнелә торган әсәрләрнең жанрларын һәм темаларын билгеләргә һәм әйтергә;
— сөйләмдә әдәби төшенчәләрне (әдәби әсәр, авторның исеме һәм фамилиясе, әсәрнең исеме) кулланырга;
— шигырь, хикәя, табышмак, мәкаль, әкият жанрларын аерырга;
— халык һәм автор әкиятләрен үзенчәлекләре буенча аерырга **өйрәнә.**

**Укучыга**

— әкият һәм шигырь, табышмак һәм мәкаль текстларын чагыштырырга;
— тексттан чагыштырулар, эндәшләрне табарга;
— тексттан геройлар арасындагы диалогны табып укырга;
— рәсеме һәм тышлыгы буенча китапның якынча темасын билгеләргә **мөмкинлек туа.**

**«Иҗади эшчәнлек» юнәлеше буенча**

**укучы**

— диалог формасындагы кечкенә әсәрләрне рольләргә бүленеп укырга;
— укылган әсәр геройлары белән төрле вакыйгалар уйларга;
— герой яки үз исеменнән әсәр эчтәлеген сөйләргә **өйрәнә.**

**Укучыга**

— укылган әсәрнең аерым эпизодларына рәсем ясарга;
— аерым эпизодларны парлап яки төркемләп сәхнәләштерергә;
— телдән кечкенә хикәя, әкият уйларга өйрәнергә **мөмкинлек туа.**

**2 нче сыйныф ахырында укучылар түбәндәге нәтиҗәләргә ирешә:**
**«Сөйләм һәм уку эшчәнлеге төрләре» юнәлеше буенча**
**укучы**

— икенче сыйныф укучысының мөмкинлекләренә туры килгән һәм укыганны аңларлык темпта бөтен сүзләр белән кычкырып **укырга (минутка 50 сүздән** ким булмаган);

— укытучы җитәкчелегендә зур булмаган әсәрне **эчтән** (үзлектән) **укырга**;

— укыла торган әсәргә туры килгән темп, тонны саклап, тыныш билгеләренә игътибар итеп, әзер текстны сәнгатьле итеп укырга;

— әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә һәм әсәр, геройлар һәм аларның эш-гамәлләре турында диалог алып барырга;

— шартлы-символик модельләштерү үрнәкләрен кулланып, китап һәм әсәрләрнең темасын, жанрын һәм авторга мөнәсәбәтен билгеләргә;

— әсәр текстыннан мәкальләрне, чагыштыруларны табарга;

— әзер план буенча өйрәнелгән әсәр эчтәлеген сөйләргә, эчтәлек сөйләү алгоритмын үзләштерергә;

— тема, жанр яки авторга мөнәсәбәте буенча китапларны төркемләргә **өйрәнә.**

**Укучы**

— укылган әсәрнең әхлакый эчтәлеген аңларга һәм аңлата белергә, гомум кулланышта булган әхлакый нормаларга таянып, геройларның эш-гамәлләре турында үз фикерен белдерергә;

— әсәр һәм өйрәнелә торган бүлек буенча мөстәкыйль сайлап алынган китапларны укыганда, эчтән уку күнекмәләрен кулланырга;

— уку максатыннан чыгып, беренчел, өйрәнү һәм эзләнү кебек уку төрләреннән файдаланырга;

— балалар өчен иҗат ителгән вакытлы матбугаттан файдаланырга һәм алардан өйрәнелә торган бүлек һәм тема буенча әсәрләр табарга **өйрәнергә мөмкин.**

**«Әдәби пропедевтика» юнәлеше буенча**

**укучы**

— шигъри һәм чәчмә әсәрләрне аерырга;

— әкият, хикәя, шигырь жанрына хас үзенчәлекләрне билгеләргә;

— мәкаль һәм табышмакларны темасы буенча аерырга;

— сөйләмдә әдәби төшенчәләрне (әкият, хикәя, шигырь, диалог, әсәр, әсәр авторы, әсәр герое) кулланырга **өйрәнә**.

**Укучы**

— әсәрләрнең әхлакый һәм эстетик **кыйммәтен аңларга**;

— әсәр, герой һәм ал арның эш-гамәлләре турында **фикерен белдерергә**;

— тексттан **чагыштыру, сынландыруларны табарга өйрәнергә мөмкин.**

**«Иҗади эшчәнлек» юнәлеше буенча**

**укучы**

— әсәр геройларының образ үзенчәлекләрен аңларга һәм рольләргә бүленеп укырга;
— зур күләмле булмаган әсәрләрне сәхнәләштерергә;
— әкиятләр сөйләргә;
— әсәр геройлары турында төрле вакыйгалар уйлап чыгарырга яки әсәрне дәвам итәргә **өйрәнә**.

**Укучы**
— өйрәнелә торган әсәрләргә иллюстрацияләр ясарга;
— әсәрнең аерым өлешләренең сүзле сурәтен «ясарга»;
— мөстәкыйль яки төркемнәрдә «Халык авыз иҗаты», «Яраткан язучыларыбыз һәм әсәрләребез» темаларына проектлар эшләргә **өйрәнергә мөмкин**.

**«Уку материалы белән эшләү» юнәлеше буенча**
**укучы**
— әсәр геройлары турында әсәрдән мәгълүмат табарга;
— текстның төп темасын һәм фикерен билгеләргә **өйрәнә**.

**Укучы**
— дәреслектән һәм белешмәлекләрдән кирәкле мәгълүматны мөстәкыйль таба белергә;
— китап аппаратыннан аның турында мәгълүмат табарга;
— модельләре буенча әсәрләрне чагыштырырга, тулыландырырга, төзәтергә, ачыкларга;
— укылган текст турында бәяләү фикерләрен әйтергә **өйрәнергә мөмкин.**

**3 нче сыйныф ахырында укучылар түбәндәге нәтиҗәләргә ирешә:**
**«Сөйләм һәм уку эшчәнлеге төрләре» юнәлеше буенча**
**укучы**
— уку тирәлеген киңәйтү өчен китап уку кирәклегенә төшенергә;
— укылган һәм тыңланган әсәрләрнең эчтәлеген аңларга, аларның төп уен билгеләргә;
— орфоэпик нормаларны саклап, өченче сыйныф укучысының мөмкинлекләренә туры килгән һәм укыганны аңларлык темпта (минутка 60—75 сүздән ким булмаган) бөтен сүзләр белән кычкырып укырга;
— укытучы җитәкчелегендә зур булмаган әсәрне эчтән укырга;
— укыла торган әсәргә туры килгән темпны, тонны саклап, тыныш билгеләренә игътибар итеп, текстны сәнгатьле итеп укырга;
— текстларны яттан сөйләргә;
— теләк буенча һәм уку максатыннан чыгып, беренчел уку, өйрәнү максатыннан уку, эзләнү максатыннан уку төрләрен кулланырга;
— әдәби, фәнни-популяр мәкалә, мәгълүмати текстларны гамәли аера белергә, охшашлык — аерымлык принцибы буенча чагыштырырга;
— әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә һәм әсәр, геройлар, аларның эш-гамәлләре турында диалог төзергә;

— әсәр һәм китап исемен дөрес атарга, әсәр исемен, аның эчтәлеккә туры килүен аңлатырга;
— әсәр геройларының эш-гамәлләрен әхлакый күзлектән чыгып бәяләргә, үзенең эмоциональ-рухи байлыгын арттырырга;
— әзер план буенча өйрәнелгән әсәр эчтәлеген сөйләргә, эчтәлекне кыскартып һәм тулысынча сөйләү төрен үзләштерергә;
— тема, жанр һәм авторга мөнәсәбәте буенча әсәрне, китапларны төркемләргә, әсәрнең үзенчәлекле якларын ачыклый белергә;
— китап төрләрен (китап-әсәр, китап-җыентык), китап, җыентыкларны темасы һәм жанры буенча аера белергә **өйрәнә.**

**Укучы**
— укылган әсәрнең әхлакый эчтәлеген аңларга, гомумкулланышта булган әхлакый нормаларга таянып, геройларның эш-гамәлләренә бәя бирергә, әсәр турында үз фикерен белдерергә;
— автор позициясен аңларга, автор фикере белән килешү— килешмәвен дәлилли белергә;
— төрле типтагы китаплар: китап-әсәр, китап-җыентык белән эшләргә, китапның тиешле структур элементларын (эчтәлек, кереш сүз, тема, автор, сүзлек) таба белергә;
— балалар өчен иҗат ителгән вакытлы матбугат, тема, жанры һәм авторга мөнәсәбәте буенча әсәрләр табу максатыннан китапханә фондыннан файдаланырга **өйрәнергә мөмкин**.

**«Әдәби пропедевтика» юнәлеше буенча**

**укучы**
— шигъри һәм чәчмә әсәрләрне аерырга; шигъри һәм чәчмә әсәрләрне атый белергә;
— 2—3 билгесе буенча әсәрнең жанр төрен (әкият, хикәя, шигырь) билгеләргә;
— әдәби әсәр текстындагы сүзләрнең синонимнарын табарга, сүзнең туры һәм контексттагы мәгънәсен аңларга;
— әсәр текстларындагы эпитетларны, чагыштыруларны, сын- ландыруларны (җанландыруларны) табарга;
— сөйләмдә жанр төрләренең исемнәрен һәм әдәби төшенчәләрне (әкият, хикәя, шигырь, тылсымлы әкиятләр, хайваннар турында әкиятләр, көнкүреш әкиятләре, диалог, әсәр, әсәр авторы, әсәр герое, чагыштыру, эпитет) кулланырга **өйрәнә**.

**Укучы**
— сүзләрнең синонимнарын табарга, сүзнең туры һәм контексттагы мәгънәсен аңларга;
— әсәрләргә анализ ясаганда, өйрәнелгән әдәби төшенчәләрне кулланырга;
— геройларның монологик сөйләмен, диалогларны табып укырга **өйрәнергә мөмкин.**

**«Иҗади эшчәнлек» юнәлеше буенча**

**укучы**

— әсәр геройларының образ үзенчәлекләрен аңларга, рольне сайларга, герой репликаларын, образга туры китереп, рольләргә бүленеп укырга;
— зур күләмле булмаган әсәрләрне яки аерым эпизодларны сәхнәләштерергә;
— әкиятләр сөйләргә;
— әсәр геройлары турында төрле вакыйгалар уйлап чыгарырга яки әсәрнең ахырын дәвам итеп сөйләргә **өйрәнә.**

**Укучы**
— өйрәнелә торган әсәрләргә иллюстрацияләр ясарга;
— әсәрнең аерым эпизодларына сүзле сурәт «ясарга»;
— темалар буенча, «Халык һәм автор әкиятләре» темасына күмәк яки шәхси проектлар эшләргә **өйрәнергә мөмкин**.

**«Уку материалы белән эшләү» юнәлеше буенча**
**укучы:**
— әсәрнең төп уен билгеләргә;
— әдәби әсәр текстында әсәр геройлары, китапның структур элементлары — авторы, жанр төре турында мәгълүмат табарга;
— әсәр текстларын кисәкләргә бүләргә, текст планнары төзергә;
— текстның төрле кисәкләрендә булган мәгълүматны чагыштырырга һәм гомумиләштерергә **өйрәнә.**

**Укучы**
— дәреслектән һәм белешмәлекләрдән кирәкле мәгълүматны мөстәкыйль таба белергә;
— китап аппаратыннан китап, китапның авторы турында мәгълүмат табарга;
— фәнни-популяр әсәр текстыннан һәм белешмәлекләрдән предмет, күренеш турында мәгълүмат туплый белергә;
— текстта булган мәгълүматны мәгълүмати чыганаклар белән чагыштырырга;
— модельләре буенча әсәрләрне чагыштырырга, тулыландырырга, төзәтергә, ачыкларга **өйрәнергә мөмкин.**

**4 нче сыйныф ахырында укучылар түбәндәге нәтиҗәләргә ирешә:**
**укучы**
— әдәби әсәрдәге рухи байлыкны аңларга һәм бәяләргә; «намуслылык», «җаваплылык», «яхшылык», «усаллык» төшенчәләрен аңлата белергә;
— үзен Россия гражданины итеп танырга, туган ил һәм дөнья әдәбияты кыйммәтләрен аңларга;
— кешеләргә игътибарлылык һәм теләктәшлек белдерергә, чит халыклар мәдәниятенә хөрмәт белән карарга;
— универсаль уку гамәлләрен (укытучы һәм сыйныфташларыңны тыңлый белүне, башкаларның фикерен һәм позициясен хөрмәт иткән хәлдә, үз позицияңне дөрес белдереп аралашуны) кулланырга;
— әсәр, китап, бүлек һәм тема буенча бирелгән проектлар өстендә мөстәкыйль, парлап яки төркемнәрдә эшләргә;

— әдәби әсәр өстендә эшләгәндә, үз эшчәнлегеңне оештырырга, регулятив универсаль уку гамәлләреннән файдаланырга **өйрәнә.**

**«Сөйләм һәм уку эшчәнлеге төрләре» юнәлеше буенча**

**укучы**

— укуга карата кызыксыну булдырырга, уку эшчәнлеген китап укучы тәҗрибәсен баету максатыннан кулланырга;
— укый белү осталыгын интеллектуаль, рухи-әхлакый, эстетик үсеш, белем һәм тәҗрибә туплау чарасы буларак кулланырга;
— укуны төрле уку бурычларын хәл итү, китап укучы мәнфәгатен канәгатьләндерү, предметара дәрәҗәдә мәгълүмат эзләү максатыннан кулланырга;
— укыганны аңларга мөмкинлек тудырырлык темпта кычкырып һәм эчтән укырга;
— орфоэпик нормаларга туры китереп, сайлап алынган яки алдан өйрәнелгән әсәрләрне сәнгатьле итеп укырга;
— укуның төрле төрләреннән (танышу максатыннан, өйрәнү максатыннан, карап чыгу максатыннан уку) файдаланырга;
— сайлап алынган уку төрен һәм формасын аңлатырга;
— әдәби, фәнни-популяр, уку һәм белешмә әсәрләрне аера белергә;
— әдәби әсәр эчтәлегендә ориентлаша белергә; мөстәкыйль рәвештә әсәрнең темасын, жанр төрен, авторга мөнәсәбәтен һәм төп уен билгеләргә; вакыйгалар үсешенең сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен, эзлеклелеген табарга; сорауларга җавап бирергә, үзе дә сораулар бирергә һәм башкаларның җавапларын тулыландырырга;
— әдәби, фәнни-популяр һәм белешмә текстлар белән эшли белергә: мәгънәсен аңларга, темасын һәм микротемаларны (подтемаларны) билгеләргә, текст буенча сорауларга җавап бирергә һәм сораулар уйларга, җавапларны тулыландырырга, цитаталар белән дәлилләргә;
— әсәр героеның эш-гамәлләрен аңларга һәм аңлатып бирергә, аларга карата үз фикерен белдерергә; автор позициясен билгеләргә;
— әсәр эчтәлеген телдән яки язмача тулы итеп, кыскартып яки сайлап алып сөйләргә;
— шигъри әсәрләрне яттан сөйләргә;
— үрнәк буенча әсәргә яки китапка кыскача аннотация язарга;
— каталогтан файдаланырга, китапханәдә кирәкле китапны үзлектән табарга **өйрәнә.**

**Укучы**

— әдәби әсәрне сәнгатьнең бер төре буларак кабул итәргә;
— автор позициясен ачыкларга һәм әсәргә, әсәр геройларына һәм аларның эш-гамәлләренә мөнәсәбәт белдерергә;
— әдәби әсәрне укыганда үзенең эмоциональ халәтендәге үзгәрешләрне билгеләргә;
— аермалы якларына басым ясап, әдәби һәм фәнни-популяр әсәрләрне чагыштырырга;

— автор текстына таянып, үз фикереңне монологик сөйләм (хикәяләү, сурәтләү, фикерләү) формасында төзергә;
— балалар өчен бастырылган вакытлы матбугат (газета, журнал) белән эшләргә **өйрәнергә мөмкин.**

**«Әдәби пропедевтика» юнәлеше буенча**

**укучы**
— әдәби, шигъри, чәчмә әсәр һәм фәнни-популяр текстларны аерырга; текст төрләрен чагыштырырга;
— төзелеше буенча фольклор әсәрләре жанрларын (әкият, җыр, мәсәл, мәкаль) чагыштырырга;
— сөйләмдә әдәби төшенчәләрне (әсәр, әсәрнең темасы һәм төп уе, әсәрнең жанры, автор, төп һәм ярдәмчел геройлар, уңай һәм тискәре герой) кулланырга;
— тексттан сәнгать чараларын (эпитет, чагыштыру, сынлан- дыру (җанландыру), метафора, гипербола) гамәли таба белергә, аларның ролен аңлатырга;
— контексттагы мәгънәсенә карап, сүзләрнең синонимнарын, антонимнарын табарга **өйрәнә.**

**Укучы**
— әдәби төшенчәләрне (шигъри һәм чәчмә әсәр, фольклор һәм автор әсәре) кулланып, текстларны чагыштырырга һәм аларга характеристика бирергә;
— тексттан әсәр геройларының монологын, диалогын, пейзаж һәм геройларның сурәтен табарга;
— «әсәр», «китап», «вакытлы матбугат» (газета, журнал) төшенчәләрен аерырга, аларны уку мәсьәләсен чишү өчен кулланырга **өйрәнергә мөмкин.**

**«Иҗади эшчәнлек» юнәлеше буенча**

**укучы**
— әдәби әсәрне рольләргә бүленеп укырга; әсәрне сәхнәләштерергә;
— аналогия буенча төрле жанр әсәрләре (табышмак, әкият, хикәя, мәсәл) уйларга;
— мөстәкыйль, парлап, төркемнәрдә иҗади проектлар төзергә; мәгълүмат тупларга, тупланган материалны кульязма китап формасында бизәргә, эш нәтиҗәләре белән конкурсларда, күргәзмәләрдә, китапханә дәресләрендә, мәктәп бәйрәмнәрендә катнашырга;
— тәкъдим ителгән тема, картина, репродукция буенча кечкенә сочинение, китап, әсәр геройлары турында бәяләмә язарга **өйрәнә**.

**Укучы**
— герой исеменнән, үз исеменнән, автор исеменнән әсәр эчтәлеген үзгәртеп сөйләргә;
— бирелгән рифма һәм строфа буенча шигырь уйларга;
— аерым эпизодларны укып, әсәр эчтәлеген сөйләргә, әсәрнең аерым эпизодларын яттан укырга;

— шәхси текстлар төзергә (аналогия буенча хикәяләргә, фикерләргә, сорауларга тулы җавап бирергә, сурәтләргә — геройларга характеристика бирергә һәм пейзажны сурәтләргә**) өйрәнергә мөмкин.**

**«Уку материалы белән эшләү» юнәлеше буенча**

**укучы**

— әсәр текстында төп һәм өстәмә **мәгълүматны таба** белергә;
— исеме һәм эчтәлеге, аннотация һәм титул бите буенча китап эчтәлеген күзалларга;
— пейзаж һәм герой портретларын сурәтләү өчен әсәр текстындагы мәгълүматны кулланырга;
— төрле мәгълүмати чаралардан (сүзлек, энциклопедия, Интернет-ресурс) файдаланырга; төрле чыганаклардан алынган мәгълүматны чагыштырырга **өйрәнә.**

**Укучы**

— белешмәлекләрдән һәм энциклопедияләрдән китап, автор турында мәгълүмат тупларга;
— тема һәм бүлекләргә тәкъдим ителгән проектларны үтәү өчен кирәкле мәгълүмат җыярга, аларны гомумиләштерә белергә **өйрәнергә мөмкин.**